Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советы

Кәвәл авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

4 апрель, 2025 ел № 2

«2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлегендә яшәүчеләрнен хокукларын үтәү максатларында «2024 елгы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге бюджетын үтәү турында» Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлегенең карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге территориясендә җәмәгать фикер алышуын һәм гавами тыңлауларны оештыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 59 номерлы (2017 елның 13 декабрендәге 77 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 97 номерлы, 2019 елнын 20 сентябрендәге 133 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 58 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 65 номерлы карарлар редакциясендә) карары белән карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге бюджетының 2024 елгы үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советынын (алга таба - Совет карары проекты) карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге башкарма комитеты;

2.2. гавами тыңлаулар уздыру датасы һәм вакыты - 2025 елның 30 апреле, 14.00 сәгать;

2.3. гавами тыңлаулар үткәрү урыны - Кәвәл авылы, Школьная урамы, 1 йорт, Кәвәл авыл мәдәният йорты фойесы;

2.4. Кәвәл авылы, Школьная урамы, 1 нче йорт адресы буенча фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, Совет карары проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга мөмкин.

3. Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Советнын карар проектын Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында

(www.pestreci.tatarstan.ru) 2025 елның 18 апреленнән дә сонга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә);

3.2. Советның билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда карары проекты буенча гавами тынлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.3. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл жирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар бәяләмәсен, шулай ук Советның эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз жаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл жирлеге
башлыгы урынбасары И.Н.Захаров